| | |
|---|---|
| СОВЕТ ХОЗЕСАНОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГОРАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ ХУҖА ХӘСӘН<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**2019 елның 14 нче июне** **Хуҗа Хәсән авылы** **№ 9**

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы «Хуҗа Хәсән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» гы Федераль законның 15нче статьясына үзгәреш кертү хакында»гы 2017 елның 29 декабрендәге 477-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлеге Советы

**КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлеге Советының 2017 елның 07 апрелендәге «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында»гы 6 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 нче бүлекне түбәндәге эчтәлекле 98.10 пункты белән тулыландырырга:

«98.10.Транспорт чараларының һәр тукталышында ,шул исәптән социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектлары янында (торак, җәмәгать һәм җитештерү бинасы, төзелмәләр һәм корылмалар, шул исәптән физкультура-спорт оешмалары, мәдәният оешмалары һәм башка

оешмалар урнашкан йортларны да кертеп) ял итү урыннарында I, II төркем инвалидлары белән идарә ителә торган транспорт чараларын түләүсез парковкалау өчен, шулай ук III төркем инвалидларына Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм мондый инвалидлар яки инвалид балаларны йөртүче транспорт чараларына урыннарның 10 процентттан да ким булмаган өлеше (кимендә 1 урын) бүлеп бирелә.Күрсәтелгән транспорт чарарларында «Инвалид»билгесе куелырга тиеш. Индивидуаль файдалану өчен «Инвалид» тану билгесен бирү тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләте биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә. Парковкалар өчен күрсәтелгән урыннар башка транспорт чаралары белән тәэмин ителергә тиеш түгел».

2.Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында "түбәндәге адрес буенча(http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең рәсми сайтында бастырып чыгарырга .

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Кайбыч муниципаль районы**
**Хуҗа Хәсән авыл җирлеге башлыгы** **Матвеева С.П.**